БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 01 2022 ел № 32

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп уку-укыту программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау турында» 2021 елның 6 ноябендәге 1417/21 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 августындагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарын.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» начальнигына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов